ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» 423-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Тыгин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» 423-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1998-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 13 пунктын, 13 статьясындагы 8 һәм 9 пунктларын, 28 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – 43-ТРЗ номерлы Закон) федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 28 апрелендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә 2024 елның 1 мартыннан башлап гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт хәрәкәтенә махсус рөхсәтләр алу өчен кирәкле барлык гамәлләр комплексы (пассажирлар йөртүче (багаж ташучы) тарафыннан махсус рөхсәт алуга гариза бирү һәм рөхсәтне алу; авыр йөкле транспорт чарасы автомобиль юлларына китерә торган зыянны каплау хисабына түләү кертү; мондый транспорт чаралары өчен хәрәкәтне оештыру проектын килештерү) «бер тәрәзә» принцибы буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырылачак.

Махсус рөхсәт бирүгә бәйле булган таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган бердәм норматив хокукый актка – Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләренә берләштереләчәк. Махсус рөхсәт бирү, шулай ук авыр йөкле транспорт чарасы автомобиль юлларына китерә торган зыянны каплау хисабына түләү күләмен билгеләү федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан башкарылачак.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проекты белән 43-ТРЗ номерлы Законның региональ, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чаралары хәрәкәтен җайга салучы нигезләмәләрен үз көчен югалткан дип танырга тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә законнарның үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Татарстан Республикасында региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянның күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 сентябрендәге 699 номерлы һәм «Татарстан Республикасында региональ яисә муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөкләр ташучы транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау турында» 2002 елның 19 сентябрендәге 551 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларының үз көчен югалтуына, шулай ук «“Юл хәрәкәте иминлеге” дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 27 февралендәге 129 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә китерәчәк.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.